# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Победа торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**29 октябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә 2022 елның 29 октябрендә "Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Победа торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә" соравы буенча узган гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

- Победа торак пунктында татар зираты территориясен төзекләндерүне оештыру (койма өчен материаллар сатып алу, койма ясау һәм урнаштыру, лаклау, буяу материалы алу);

- урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- муниципаль тракторга тагылмалы арба сатып алу;

- бәйрәм чараларын оештыру һәм уздыру («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын уздыру хезмәтләре, бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);

- Победа торак пункты территориясе төзекләндерүне оештыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен тракторчыга түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 421 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 295 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "РИЗА" позициясе өчен җыенда 295 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Победа торак поуктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. “Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Победа торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Победа торак пунктында татар зираты территориясен төзекләндерүне оештыру (койма өчен материаллар сатып алу, койма ясау һәм урнаштыру, лаклау, буяу материалы алу);

- урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- муниципаль тракторга тагылмалы арба сатып алу;

- бәйрәм чараларын оештыру һәм уздыру («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын уздыру хезмәтләре, бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);

- Победа торак пункты территориясе төзекләндерүне оештыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен тракторчыга түләү) соравы буенча үзара салым кертү буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районының
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Г.И. Әскәрова